| СОВЕТ КУЛАНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2022 Колаңгы т.юл ст. № 40

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» 2014 елның 14 октябрендәге 26 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»

Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» 2014 елның 14 октябрендәге 26 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәгә, 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«в) (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш ясаганга кадәрге өч ел эчендәге гомуми кеременнән артып китсә, ул килешүгә кул куелганчы, җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru, авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Колаңгы авыл җирлеге Башлыгы                                        Ф.Т.Нигматзянов